| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 март 2014 ел Казан шәһәре № 6-14/тп

***ЯАЖ «ЧАЛЛЫ СУ КАНАЛЫ» салкын су белән тәэмин итү үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру)өчен тарифлар билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 13 май, 2013 ел, 29 июль 2013 ел №644 Россия Федерациясе карары белән расланган, Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында кагыйдаләре нигезендә, “Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны тәртипкә салуда методик киңәшләрне раслау турында” Тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 27 декабрь 2013 ел №1746-э боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт КАРАР БИРӘ:

1. ЯАЖ «ЧАЛЛЫ СУ КАНАЛЫ» салкын су белән тәэмин итү үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен тарифларны әлеге карарның кушымтасына килештереп билгеләргә.
2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
28 март 2014 ел № 6-14/тп

ЯАЖ «ЧАЛЛЫ СУ КАНАЛЫ» салкын су белән тәэмин итү үзәк системасына тоташтыру (технологик тоташтыру) тарифлары

| № п/п | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тариф (ӨБС исәпкә алынмаган) |
|---|---|---|---|
| 1 | Тоташтыру йөкләнеше өчен база тарифы | мең.сум/$м^3$ сәгатенә | 3,857 |
| 2 | Челтәрнең озынлыгы тарифы база ставкасы | мең.сум/м | 19,222 |
| 3 | Челтәрнең диаметрына карата тарифның дифференциация коэффициенты: | | |
| 3.1 | 40 мм диаметрлы һәм аннан кече булган | - | 0,30 |
| 3.2 | 40 мм - 70 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | 0,38 |
| 3.3 | 70 мм - 100 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | 0,49 |
| 3.4 | 100 мм - 150 мм кадәр диаметрлы (эченә алып) | - | 0,52 |
| 3.5 | 150 мм - 200 мм диаметрлы (эченә алып) | - | 0,60 |
| 3.6 | 200 мм - 250 мм диаметрлы (эченә алып) | - | 0,77 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге